

Татарстан Фәннәр академиясенен Галимжан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты vзенен оешкан коненнән башлап, ягъни 84 ел дәвамында татар халкынын рухи һәм милли-мәдәни мирасын барлау, туплау, ойрәнv белән шогыльләнә. Институтнын Язма һәм музыкаль мирас vзәгендә Мордовия олкәсенә караган фольклор материаллары саклана. Алар, нигездә, фәнни экспедиция вакытында шул тобәктә гомер итvче халыктан жыелган.

Мордовия тобәгенен татарлар яшәгән авылларына Институтнын ин беренче фольклор экспедициясе 1957 елнын 31 июленнән алып 1 сентябренә кадәр танылган фольклорчы галим филология фәннәре докторы Хәмит Ярми житәкчелегендә оештырыла. Экспедиция эшендә дvрт фольклорчы катнаша. Алар ике торкемгә бvленеп эшлиләр. Беренче торкем галимнәре Х.Ярми (житәкче) һәм Х.Гатина Ләмбрә районы Ләмбрә, Талаелау, Пензятка, Свәрби, Тат.Тавла, Аксеново, Кадошкин районы Иса (Б.Поляна), Латыш, Рузаевка районы Үгенә, Тат.Пешлә авылларын ойрәнәләр. Икенче торкем – И.Надиров (отряд житәкчесе) һәм Р.Кәримов Пурдошан районы Кадыш, Вачеевка, Лобановка, Митрял, Темников районы Олы Карай, Тархан, Атюрьево районы Тvбән Пешлә, Олы Кыштыру, Торбеево районы Сыркыды (Сургодь) авылларында тикшеренvләр уздыралар. Барлыгы 7 районнын 19 татар авылында булалар. Аларнын экспедиция хисапларына кvз салсак, тvбәндәгеләрне кvрәбез: 9 әкият, 29 бәет, 3923 жыр, 296 сюжетлы жыр, 7 уен жыры, 8 сойләк, истәлек, авыл тарихына караган риваять, 1 легенда, 84 мәкаль һәм әйтем, 11 табышмак кебек халык ижаты жанрларына караган vрнәкләр язып алып кайталар. Шулай итеп, Институт хезмәткәрләре фән очен бик кыйммәтле халык ижаты материалларын бортекләп жыеп йориләр һәм аларга ярдәм иткән кешеләрнен исемнәре теркәлеп куелган.

Мордовия татарларынын сойлә-шләрен ойрәнер очен Институтнын телче-диалектологлары да әлеге тобәккә берничә тапкыр экспедициягә чыгалар. Татар сойләшләре Атласына кvз салсак, Темников районы Тvви (1956), Митрял, Адай (1956, 1979), Тархан (1956), Ельников районы Яна Кадыш (1956), Краснослободский районы Черный (1956), Атюрьево районы Тvбән Пишли (1956), Виләзмә (1956, 1970), Ена Аллагол (1970), Торбеево районы Янә (Татар.Юнки, 1970), Сыркыды (1956), Рузаевка районы Пешлә (1957), Ләмбрә районы Сырка, Азёрка, Ләмбрә, Пензятка (1957), Ромоданово районы Тавла (1957), Дубенка районы Ламат (1969), Зубово-Полянский районы Горенка (1970), Искил (Татар Лундан, 1959), Инсар районы Иса (1970), Латыш, Яндавище (1967), Рузаевка районы Шепбас, Үгенә (1967), Кочкур районы Татар Ымызы (1969) авыллары тикшерелә.

Мордовия тобәгендә тупланылган материаллар галимнәрнен монографик хезмәтләрендә, жыентыкларда һәм татар халык сойләшләренен атласында урын ала. Шулай итеп, узган гасырдан бирле диалектологик һәм фольклор материаллары жыю очен галимнәрнен Мордовия Республикасына чыкканы булмаган. Шуна кvрә бу тобәккә берничә олкәгә кагылышлы тикшеренvләрне максат итеп куйган комплекслы фәнни экспедициягә 2023 елнын 19 июненнән юлга чыгарга ниятлибез. Олкәнен, момкин булган

кадәр, Ләмбрә һәм Ромоданово районнарынын татар авылларында экспедиция барлыгы 10-12 кон булачак. Анын составында татар халык ижатын ойрәнvче фольклорчы, сойләшләрне ойрәнvче телче-диалектолог, борынгы, иске китапларны ойрәнvче археограф, борынгы каберташлары язмаларын ойрәнvче эпиграфика белгече, осталарны һәм аларнын кул эшләрен ойрәнvче  сәнгатьче, кой-музыка белән башкарыла торган әсәрләрне һәм уен коралларын ойрәнvче музыкаль фольклор белгече эшләячәк. Галимнәрнен килvе турында алдан хәбәр итvнен максаты шул: халкыбызнын рухи жәvһәрләрен туплау эшенә хәленнән килгән кадәр һәркем олеш кертә ала.
Хормәтле милләттәшләр! Сезгә vтенечебез бар: галимнәр белән аралашыр очен вакытыгызны кызганмыйча, хәтерегездә калган халык ижаты әсәрләрен (әкиятләр, жырлар, бәетләр, монәжәтләр, риваятьләр-легендалар, халык уеннары һ.б.), йолаларны, койләрне, әби-бабалардан калган, сандык топләрендә ята торган гарәп язулы кулъязмаларны, иске китапларны, милли бизәкле солгеләрне һәм торле кул эшләре әйберләрен, гомумән, татар халкынын мирасына кагылышлы ядкарьләрне барласагыз иде. Без аларны язып яисә тошереп алырбыз. Сезнен ярдәмегез белән мирасыбыз тулылана, тарихыбыз, мәдәниятебез байый. Мордовиянен гап-гади кешеләреннән – татар халкы вәкилләреннән экспедиция әгъзалары тарафыннан жыелган материаллар якын арада китап булып донья кvрер дип котелә. Тиздән очрашканга кадәр!

**Ильмир ЯМАЛТДИНОВ,** *филология фэннэре кандидаты, экспедиция житэкчесе*